КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 май г.Казань № 321

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 31 декабрь, 1097 нче карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 31 декабрь, 1097 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 10 июнь, 393 нче; 2014 ел, 6 декабрь, 955 нче;

2015 ел, 3 октябрь, 739 нчы; 2017 ел, 27 октябрь, 813 нче; 2017 ел, 22 декабрь, 1021 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1269 нчы; 2019 ел, 1 ноябрь, 994 нче; 2020 ел, 15 октябрь, 930 нчы; 2021 ел, 30 декабрь, 1348 нче; 2022 ел, 9 март, 211 нче; 2022 ел, 19 сентябрь, 1017 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлектә:

1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче таблица

Учреждениеләр (аерымланган бүлекчәләр) төркеменә бәйле рәвештә, хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү буенча билгеләнә торган вазыйфаи окладлары

| Т/с | Хезмәткәрләр вазыйфалары | Учреждениеләр (аерымланган бүлекчәләр) төркемнәре буенча вазыйфаи оклад күләме, сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | I | II | III | IV |
| 1. | Учреждение җитәкчесе (башлыгы) | 40 023 | 34 074 | 32 567 | 31 239 |
| 2. | Учреждениядәге идарә, хезмәт, штаб, үзәк башлыгы | 31 239 | 29 894 | 28 714 | 27 552 |
| 3. | Мөстәкыйль бүлек башлыгы | 29 894 | 28 714 | 27 552 | 26 470 |
| 4. | Учреждениядәге идарә, хезмәт, штаб, үзәк составындагы бүлек; вәкиллек, мөстәкыйль бүлек (төркем) башлыгы | 28 714 | 27 552 | 26 470 | 25 291 |
| 5. | Бүлек составындагы бүлек (төркем) башлыгы | 27 552 | 26 470 | 25 291 | 24 206 |
| 6. | Эзләү-коткару отряды башлыгы | 42 729 | 36 187 | 34 507 | 33 074 |
| 7. | Янгынга каршы хезмәт отряды башлыгы | 32 567 | 31 239 | 29 894 | 28 714 |
| 8. | Янгын часте башлыгы, янгынга каршы хезмәтнең аерым посты | 30 878 | 29 698 | 28 535 | 27 453 |
| 9. | Янгынга каршы хезмәт отряды буенча оператив кизү торучы | 26 272 | 25 191 | 24 190 | 23 273 |
| 10. | Янгынга каршы хезмәт отряды башлыгының матди-техник тәэмин итү буенча ярдәмчесе | 26 470 | 25 291 | 24 206 | 23 209 |
| 11. | Янгынга каршы хезмәтнең җитештерү һәм техник үзәге, янгынга каршы хезмәтнең укыту үзәге башлыгы | 29 894 | 28 714 | 27 552 | 26 470»; |

2 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче таблица

Учреждениеләр (аерымланган бүлекчәләр) төркеме нинди булуга карамастан, хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү буенча билгеләнә торган вазыйфаи окладлары

| Т/с | Хезмәткәрләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Идарә пункты башлыгы | 25 291 |
| 2. | Учреждение составындагы идарә пункты башлыгы | 23 209 |
| 3. | Химия-радиометрия лабораториясе башлыгы | 25 291 |
| 4. | Уку-укыту һәм методика кабинеты мөдире | 25 291 |
| 5. | Учреждениенең оператив кизү торучысы | 23 209 |
| 6. | Идарә пунктының оператив кизү торучысы | 24 206 |
| 7. | Оператив кизү торучының ярдәмчесе | 22 288 |
| 8. | Төп эшчәнлек буенча инспектор (өлкән инспектор): | |
| | инспектор | 22 288 |
| | өлкән инспектор | 24 206 |
| 9. | Коткаручы: | |
| | халыкара класслы коткаручы | 31 597 |
| | беренче класслы коткаручы | 30 289 |
| | икенче класслы коткаручы | 29 010 |
| | өченче класслы коткаручы | 27 830 |
| | коткаручы | 26 520 |
| 10. | Су астында эшләүче белгеч: | |
| | су астында эшләүче өлкән белгеч | 27 552 |
| | су астында эшләүче белгеч | 26 470 |
| 11. | Гражданнар оборонасы белгече (төп белгеч): | |
| | төп белгеч | 26 470 |
| | беренче категорияле белгеч | 25 291 |
| | икенче категорияле белгеч | 24 206 |
| | гражданнар оборонасы белгече | 23 209 |
| 12. | Янгын часте каравылы башлыгы, янгынга каршы хезмәтнең аерым посты | 26 108 |
| 13. | Янгынга каршы хезмәтнең күчмә насос станциясе башлыгы | 23 209 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 14. | Янгынга каршы хезмәтнең газ һәм су белән сүндерелә торган күчмә җайланма башлыгы | 23 209 |
| 15. | Янгынга каршы хезмәтнең янгын сүндерү часте (аерым посты) бүлеге командиры | 25 191 |
| 16. | Янгынга каршы хезмәтнең янгын сүндерү частендә газдан һәм төтеннән саклау мастеры | 24 206 |
| 17. | Янгын сүндерү часте (аерым посты) диспетчеры | 22 288 |
| 18. | Янгынга каршы хезмәт (янгын сүндерү часте) отряды инженеры: | |
| | төп инженер | 26 470 |
| | беренче категорияле инженер | 24 206 |
| | икенче категорияле инженер | 23 209 |
| | инженер | 22 288 |
| 19. | Янгынга каршы хезмәтнең янгын чыгуны профилактикалау инструкторы | 20 617 |
| 20. | Янгынга каршы хезмәтнең янгын сүндерүчесе*: | |
| | беренче класслы янгын сүндерүче | 25 223 |
| | икенче класслы янгын сүндерүче | 24 206 |
| | өченче класслы янгын сүндерүче | 23 290 |
| | янгын сүндерүче | 22 371 |
| 21. | Коткару станциясе башлыгы | 25 291 |
| 22. | Пост (коткару) башлыгы | 21 454 |
| 23. | Маневрлы эзләү төркеме башлыгы | 27 552 |
| 24. | Су астында йөри, коткара торган судно капитаны-механигы | 22 288 |
| 25. | Патруль, коткару катеры капитаны (өлкән моторчы-рулевой) | 20 617 |

*Янгын сүндерүчеләргә класс бирү Учреждение оештыра торган квалификация комиссиясе тарафыннан һәм Учреждение җитәкчесенең боерыгы белән расланган нигезләмәгә таянып гамәлгә ашырыла.»;

3 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 нче таблица

Өстәмә һөнәри белем бирү учреждениеләре мөгаллимнәренең вазыйфаи окладлары

| Вазыйфа исеме | Профессорлар һәм мөгаллимнәр составының гыйльми дәрәҗәсе исәпкә алынган вазыйфаи окладлары күләмнәре, сум | |
|---|---|---|
| | гыйльми дәрәҗәсе булмаган | фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәсе булган |
| Өлкән мөгаллим | 28 714 | 34 074 |
| Мөгаллим | 26 470 | 31 239»; |

4 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 нче таблица

«Гомумтармак вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары

| Т/с | Хезмәткәрләрнең категорияләре һәм вазыйфалары | Вазыйфаи окладлары, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Җитәкче | | |
| 1. | Канцелярия мөдире: | |
| | документлар әйләнешенең күләме елына 25 мең документка кадәр булганда | 19 867 |
| | документлар әйләнешенең күләме елына 25 мең документтан артыграк булганда | 20 617 |
| 2. | Склад мөдире | 20 617 |
| 3. | Үзәк склад мөдире | 21 454 |
| 4. | Уку-укыту һәм методика кабинеты мөдире | 25 291 |
| 5. | Гараж башлыгы | 26 470 |
| 6. | Радиостанция башлыгы | 24 206 |
| Белгечләр | | |
| 7. | Китапханәче, библиограф: | |
| | төп китапханәче, библиограф | 26 470 |
| | беренче категорияле китапханәче, библиограф | 25 291 |
| | икенче категорияле китапханәче, библиограф | 23 209 |
| | китапханәче, библиограф | 21 454 |
| 8. | Бухгалтер: | |
| | төп бухгалтер | 26 470 |
| | беренче категорияле бухгалтер | 24 206 |
| | икенче категорияле бухгалтер | 22 288 |
| | бухгалтер | 20 617 |
| 9. | Бухгалтер-ревизор: | |
| | төп бухгалтер-ревизор | 26 470 |
| | беренче категорияле бухгалтер-ревизор | 24 206 |
| | икенче категорияле бухгалтер-ревизор | 23 209 |
| | бухгалтер-ревизор | 22 288 |
| 10. | Эзләү-коткару хезмәтенең гомуми практика табибы | 26 470 |
| | Квалификация категориясе булганда: | |
| | югары категорияле табиб | 29 894 |
| | беренче категорияле табиб | 28 714 |
| | икенче категорияле табиб | 27 552 |
| 11. | Баш белгеч (Учреждение бүлекләрендә, лаборатория- | 26 928 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | ләрендә, идарәләрендә, хезмәтләрендә, штабларында, үзәкләрендә) | |
| 12. | Ашыгыч чакыруларны эшкәртү үзәгенең баш белгече | 26 928 |
| 13. | Диспетчер (өлкән диспетчерны кертеп): | |
| | өлкән диспетчер | 20 617 |
| | диспетчер | 19 867 |
| 14. | Документлар белгече: | |
| | өлкән документлар белгече | 26 470 |
| | беренче категорияле документлар белгече | 24 206 |
| | икенче категорияле документлар белгече | 23 209 |
| | документлар белгече | 21 454 |
| 15. | Инженер (барлык атамалардагы): | |
| | төп инженер | 26 470 |
| | беренче категорияле инженер | 24 206 |
| | икенче категорияле инженер | 23 209 |
| | инженер | 21 454 |
| 16. | Инспекторлар: кадрлар буенча, йөкләмәләрнең үтәлешен контрольдә тоту буенча (өлкән инспекторларны кертеп): | |
| | өлкән инспектор | 20 617 |
| | инспектор | 19 867 |
| 17. | Контракт белән идарә итүче | 25 291 |
| 18. | Корректор: | |
| | өлкән корректор | 23 209 |
| | корректор | 22 288 |
| 19. | Лаборант (өлкән лаборантны кертеп): | |
| | өлкән лаборант | 20 617 |
| | лаборант | 19 867 |
| 20. | Персонал буенча менеджер | 26 470 |
| 21. | Механик | 21 454 – 26 470 |
| 22. | Тәрҗемәче: | |
| | төп тәрҗемәче | 26 470 |
| | беренче категорияле тәрҗемәче | 24 206 |
| | икенче категорияле тәрҗемәче | 23 209 |
| | тәрҗемәче | 21 454 |
| 23. | Программист: | |
| | өлкән программист | 28 714 |
| | беренче категорияле программист | 26 470 |
| | икенче категорияле программист | 24 206 |
| | программист | 22 288 |
| 24. | Психолог*: | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | төп психолог | 26 470 |
| | беренче категорияле психолог | 25 291 |
| | икенче категорияле психолог | 24 206 |
| | психолог | 23 209 |
| 25. | Җитәкче секретаре | 26 470 |
| 26. | Система администраторы: | |
| | баш система администраторы | 28 714 |
| | төп система администраторы | 26 470 |
| | өлкән система администраторы | 25 291 |
| | система администраторы | 24 206 |
| 27. | Документлар белән тәэмин итү белгече | 25 291 |
| 28. | Белгеч (геомәгълүмат системалары буенча): | |
| | төп белгеч (геомәгълүмат системалары буенча) | 26 470 |
| | белгеч (геомәгълүмат системалары буенча) | 24 206 |
| 29. | Сатып алулар буенча белгеч: | |
| | сатып алулар буенча төп белгеч | 26 470 |
| | сатып алулар буенча өлкән белгеч | 24 206 |
| | сатып алулар буенча белгеч | 21 454 |
| 30. | Кадрлар буенча белгеч | 22 288 |
| 31. | Кадрлар эшен башкару буенча белгеч | 22 288 |
| 32. | Персонал буенча белгеч | 24 206 |
| 33. | Хезмәтне саклау буенча белгеч | 25 291 |
| 34. | Ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча белгеч: | |
| | ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча баш белгеч | 26 928 |
| | ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча төп белгеч | 25 191 |
| | ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча өлкән белгеч | 24 190 |
| | ашыгыч чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча белгеч | 23 209 |
| 35. | Мобилизация эше буенча белгеч | 26 470 |
| 36. | Җәмәгатьчелек белән элемтәләр белгече | 26 470 |
| 37. | Техник: | |
| | беренче категорияле техник | 21 454 – 23 209 |
| | икенче категорияле техник | 20 617 |
| | техник | 19 867 |
| 38. | Эзләү-коткару хезмәте фельдшеры | 23 209 |
| | Квалификация категориясе булганда: | |
| | югары категорияле фельдшер | 26 470 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | беренче категорияле фельдшер | 25 291 |
| | икенче категорияле фельдшер | 24 206 |
| 39. | Рәссам: | |
| | төп рәссам | 26 470 |
| | беренче категорияле рәссам | 24 206 |
| | икенче категорияле рәссам | 23 209 |
| | рәссам | 21 454 |
| 40. | Икътисадчы (барлык атамалардагы): | |
| | төп икътисадчы | 26 470 |
| | беренче категорияле икътисадчы | 24 206 |
| | икенче категорияле икътисадчы | 23 209 |
| | икътисадчы | 21 454 |
| 41. | Юрисконсульт: | |
| | төп юрисконсульт | 26 470 |
| | беренче категорияле юрисконсульт | 24 206 |
| | икенче категорияле юрисконсульт | 23 209 |
| | юрисконсульт | 21 454 |
| | Техник башкаручылар | |
| 42. | Архивчы | 19 867 |
| 43. | Пропускларның дежур бюросы | 19 242 |
| 44. | Кизү торучы (белешмә кәгазьләре бирү, зал, кунакханә каты, ял итү бүлмәсе, тулай торак һ.б. буенча) | 19 867 |
| 45. | Эш башкаручы | 19 552 |
| 46. | Кассир: | |
| | өлкән кассир | 19 867 |
| | кассир | 19 552 |
| 47. | Комендант | 20 617 |
| 48. | Тикшереп үткәрү пункты контролеры | 19 867 |
| 49. | Секретарь | 19 867 |
| 50. | Секретарь-администратор | 24 206 |
| 51. | Секретарь-машинистка: | |
| | беренче категорияле секретарь-машинистка | 19 867 |
| | икенче категорияле секретарь-машинистка | 19 552 |
| 52. | Экспедитор | 19 242 |
| 53. | Йөкләр ташу буенча экспедитор | 19 552 |

*Гадәттән тыш хәлләр салган зыяннарны бетергәндә ашыгыч ярдәм күрсәтү бурычларын хәл итү өчен билгеләнгән махсус күчмә бүлекчәләр психологларына (биләгән вазифасы нинди булуга карамастан) вазифаи окладлар 20 процентка арттырыла.

Учреждениедә махсус күчмә бүлекчәләрнең булуы Учреждениенең штат расписаниесендә күрсәтелергә тиеш.»;

5 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 нче таблица

Эшчеләр вазыйфалары буенча һөнәри эшчәнлек гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең тариф ставкалары

| Тариф ставкалары төркемнәре | I | II | III | IV | V | VI | VII | VIII | IX |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Тарифлар ставкасы күләме, сум | 19 242 | 19 473 | 19 783 | 20 098 | 20 848 | 21 685 | 22 519 | 23 440 | 24 457 – 26503»; |

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Су астына төшеп эшләү, кыска вакытка су астына төшү ысулы һәм югары басым астында озак булу ысулы белән сулыш алу өчен ясалма газ катнашмаларын кулланып барокамераларда билгеләнгән эш басымы астында булу вакыты өчен су астында эшләүчеләргә, су астында эшләргә тиешле рөхсәтләре булган һәм хезмәт вазыйфаларын башкару өчен су астына төшкән башка хезмәткәрләргә*, шулай ук зыян күргән су астында эшләүчеләргә ярдәм күрсәтүдә, дәвалый торган рекомпрессия ясауда катнашучы медицина персоналына, аларның окладыннан (вазыйфаи окладыннан башка), 7 нче таблица нигезендә сәгать исәбеннән түләү билгеләнә.

---

*Башка хезмәткәрләргә түбәндәгеләр керә: халыкара класслы коткаручылар, 1, 2, 3 класслы коткаручылар, коткаручылар (классыз), янгын сүндерүчеләр, барлык дәрәҗәләрдәге эзләү-коткару һәм янгын сүндерү бүлекчәләре башлыклары, су астында эшләүчеләр медицинасы буенча табиблар һәм фельдшерлар, су астында эшләүчеләр станцияләре, постлар старшиналары, су астында эшләүче матрослар, су астында эшләүче инструкторлар, су астында эшләүче белгечләр (шул исәптән баш, өлкән), су астында эшләргә әзерләү буенча укытучылар, уку-укыту һәм күнекмәләр ясау комплекслары һәм су астына төшүчеләр полигоннары башлыклары, хезмәт йөкләмәләрен башкару өчен су астына төшүче башка хезмәткәрләр.».

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин